ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__23____ «_13_»____01_____2017 ел.

«2017 елга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген арттыру»
максатчан программасы турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру " федераль максатчан программасы Концепциясен раслау турында” 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы күрсәтмәсен, "2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру" Федераль максатчан программасы турында" 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы РФ Хөкүмәте карарын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел, 6 декабрь, ПУ-1115 нче Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору дәүләт программасын раслау турында” 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче санлы карарын үтәү максатларында, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл - транспорт һәлакәтләре санын киметү һәм аларның авыр нәтиҗәләрен киметү буенча өстәмә чаралар турында»29.12.2015 ел, №1002 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә к а р а р б и р ә м:

1.«2017 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» максатчан программасын (алга таба – программа) расларга. (1 нче кушымта)

2. Финансово-бюджетной палате Мамадышского муниципального района, исполнительному комитету г. Мамадыш, отделам территориального, инфраструктурного развития, МКУ «Отдел образования» исполнительного комитета Мамадышского муниципального района РТ, МУ "Отдел по делам молодежи и спорту" исполнительного комитета Мамадышского муниципального района РТ, МУ «Отдел культуры исполнительного комитета Мамадышского муниципального района Республики Татарстан», ГАУЗ "Мамадышская центральная районная больница" при формировании бюджета района и программы капитальных вложений предусматривать средства на реализацию мероприятий Программы.

3. Тәкъдим итәргә:

- Мамадыш шәһәре һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә, «Мамадыш ЖКУ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, «Татавтодор» ОАО Мамадыш филиалына торак пунктларда урам-юл челтәрен һәм юл хәрәкәтен техник җайга салу чараларын сыйфатлы карап тоту буенча чаралар үтәлешен тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф бүлеге» МКУ нә гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне гамәлгә ашыручы автотранспорт йөртүчеләрнең һөнәри осталыгы дәрәҗәсенә, мәктәп автобусларының техник халәтенә карата булган таләпләрне арттырырга;
- территориаль инфраструктур үсеш бүлекләренә, Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты «Мәгариф бүлеге» МКУ , Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ, Мамадыш үзәк район хастаханәсенә, Мамадыш районы эчке эшләр бүлегенең ГИБДД бүлегенә Программаның үтәлеше турында квартал саен анализ ясарга һәм мәгълүматны һәр айның 5 нче числосына кадәр муниципаль районы башкарма комитетына хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.Э.Фәттахов